РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**СОВЕТ ЧИСТОПОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

тел. (84342) 5-43-60, тел/факс 5-43-70, E-mail: chistay@tatar.ru

№ 39/1 — 2018 елның 23 ноябре

Решение — Карар

Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында”гы 131нче Федераль законының 44нче маддәсе, 2004 елның 28 июлендәге “ Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 45 нче ТРЗының 7 нче маддәсе**,** Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставының 85-87 нче маддәләре нигезендә Чистай муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ:**

1.Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына Чистай муниципаль районы Советының 29.01.2014елгы 32/1нче карары белән (Чистай муниципаль районы Советының 28.04.2015елгы 45/1нче, 18.12.2015елгы 3/4нче, 10.02.2017елгы 17/2нче, 07.08.2017елгы 23/1нче , 29.03.2018елгы 32/1 нче карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6нчы маддәнең 1 нче пунктында:

1.1.1. 5нче пунктчада “район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле билгеләнештәге автомбиль юлларының сакланышы өчен” дигән сүзләрдән соң “, юл хәрәкәтен оештыру” дигән сүзләрне өстәргә;

1.1.2. 6нчы пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“16) район территориясендә каты коммуналь калдыкларны туплау ( шул исәптән аерым туплау), җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу”;

1.1.3. 39 нчы пунктчаны үз көчен югалткан дип табарга;

1.2. 6.1нче маддәдә:

1.2.1. 2нче пунктта “ авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле билгеләнештәге автомбиль юлларының сакланышы өчен” дигән сүзләрдән соң “, юл хәрәкәтен оештыру” дигән сүзләрне өстәргә;

1.2.2. 12нче пунктны түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга “,планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү ( алга таба - планлаштырылган төзелеш турында белдерү) турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән параметрларга тәңгәл килүе һәм шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын җир участогында урнаштыру мөмкинлеге турында белдерү, планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү яки реконструкцияләү (алга таба - планлаштырылган төзелеш турында белдерү) турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән параметрларга тәңгәл килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын җир участогында урнаштыру мөмкин булмавы турында белдерү, җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир участокларында шәхси торак яки бакча йорты объектын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак яки бакча йорты объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә тәңгәл килүе яки тәңгәл килмәве турында белдерү җибәрү, Россия Федерациясенең гражданнар законы нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турында карар кабул итү, рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турында карар, яки аны билгеләнгән җирдән файдалану һәм корылмалар төзү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү кагыйдәләре белән рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларын территорияне планлаштыру яки федераль законнар нигезендә билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларының мәҗбүри таләпләре белән тәртипкә китерү (алга таба – билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китерү), максатчан билгеләнештә файдаланылмый яки Россия Федерациясе законын бозып файдаланыла торган җир участогын тартып алу турында карар, рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү яки аны Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китерү”;

1.3. 7нче маддәнең 1 нче пунктында:

1.3.1. 10нчы пунктча үз көчен югалткан дип табарга;

1.3.2. түбәндәге эчтәлектәге 14нче пунктча белән тулыландырырга:

«14) Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән “Кулланучылар хокукы турында”гы 2300-1нче Законында каралганча, кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашырырга”;

1.4. 16нчы маддәнең 2нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Ачык тыңлаулар халык, район Советы, район Башлыгы яки районның башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча уздырыла. Халык, яки район Советы инциативасы уздырылучы ачык тыңлаулар район Советы тарафыннан билгеләнә, район Башлыгы яки районның башкарма комитеты Җитәкчесе инициативасы буенча уздырылучы ачык тыңлаулар район Башлыгы тарафыннан билгеләнә”;

1.5. 25нче маддәдә:

1.5.1. 1нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Район Советы депутатының вәкаләтләре  район составына керүче авыл җирлеге башлыгының үз вазифасына керү көненнән яки әлеге җирлекнең вәкаләтле органы депутатын район Советына депутат итеп сайлаган көннән башлана һәм шул рәвешле авыл җирлегенең яңадан сайланган башлыгы вазифасына керү көнннән яки әлеге җирлектән депутатны район Советы составына  чираттагы сайлау турында карар үз көченә кергән көннән тәмамлана.”;

1.5.2. 7нче пунктның  2 нче пунктчасында:

1.5.2.1.”сәяси партия” дигән сүзләрдән соң “билгеләнгән тәртиптә теркәлгән профсоз тарафыннан” дигән сүзләрне өстәргә;

1.5.2.2. “федераль законнар белән каралган очраклардан,  һәм әгәр оешма идарәсендә катнашу Россия Федерациясе законы нигезендә җирле үзидарә органы  исеменнән  гамәлгә ашырыла дигән очраклардан” дигән сүзләрне түбәндәге  сүзләр белән алмаштырырга: “бушлай нигездә Россия Федерациясе Президенты  яки Россия Федерациясе Хөкүмәте  актлары нигезендә оештырылган коллегиаль орган эшчәнлегендә катнашу; бушлай нигездә оештыручысы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган  идарә органнарында һәм  оешманың ревизия комиссиясендә  муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен; муниципаль берәмлек исеменнән оешманы оештыручы яки муниципаль милектә булган акцияләр белән (устав капиталында өлешләр белән катнашу) идарәсе вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә тәкъдим итү; федераль закон белән каралган башка очраклар;

1.6. 42 нче маддәнең 1 пунктында:

1.6.1. 3 нче пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-район территориясендә  каты коммуналь калдыкларны туплау ( шул исәптән аерым  туплау), җыю, транспортировкалау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү  буенча эшчәнлекне оештыруда катнашалар;”;

1.6.2. 4нче пунктчаның икенче абзацында “район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән тыш җирле билгеләнештәге автомбиль юлларының сакланышы өчен” дигән сүзләрдән соң  “, юл хәрәкәтен оештыра” дигән сүзләрне өстәргә;

1.6.3. 5 нче пунктчаның  унҗиденче абзацы үз көчен югалткан дип  табарга;

1.6.4. 8.1 пунктчасында:

1.6.4.1. өченче абзацта авыл җирлекләре торак пунктлары чикләрендә җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының сакланышы өчен” дигән сүзләрдән соң “, юл хәрәкәтен оештыра” дигән сүзләрне өстәргә;

1.6.4.2. унберенче абзацны түбәндәге сүзләр белән тулыландырырга: “,планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү  яки реконструкцияләү ( алга таба -  планлаштырылган төзелеш турында белдерү) турындагы белдерүдә күрсәтелгән шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән  параметрларга  тәңгәл килүе һәм шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын  җир участогында урнаштыру мөмкинлеге турында  белдерү, планлаштырылган шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын төзү  яки  реконструкцияләү ( алга таба - планлаштырылган төзелеш турында белдерү) турындагы белдерүдә күрсәтелгән

шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объекты параметрларының билгеләнгән параметрларга тәңгәл килмәве һәм (яки) шәхси торак төзелеше яки бакча йорты объектын җир участогында урнаштыру мөмкин булмавы турында белдерү, җирлекләр территорияләрендә урнашкан җир участокларында шәхси торак яки бакча йорты объектын төзегәндә һәм реконструкцияләгәндә төзелгән яки реконструкцияләнгән шәхси торак яки бакча йорты объектының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы закон таләпләренә тәңгәл килүе яки тәңгәл килмәве турында белдерү җибәрә, Россия Федерациясенең гражданнар законы нигезендә рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турында карар кабул итә, рөхсәтсез төзелгән корылмаларны сүтү турында карар, яки аны билгеләнгән җирдән файдалану һәм корылмалар төзү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү кагыйдәләре белән рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларын территорияне планлаштыру яки федераль законнар нигезендә билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларының мәҗбүри таләпләре белән тәртипкә китерә (алга таба – билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китерү), максатчан билгеләнештә файдаланылмый яки Россия Федерациясе законын бозып файдаланыла торган җир участогын тартып алу турында карар, рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтүне гамәлгә ашыра яки аны Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексында каралган очракларда билгеләнгән таләпләр нигезендә тәртипкә китерә”;

1.6.5. 9 пунктчада:

1.6.5.1. алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“-федераль законнр нигезендә билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрүне оештыру өчен шартлар булдыра, шулай ук ведомство карамагындагы оешмалар җитәкчеләренең эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен кабул итә һәм федераль законнр нигезендә үткәрелгән оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартлары сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган кимчелекләрне бетерү буенча чаралар кабул итүгә контрольне гамәлгә ашыра;”;

1.6.5.2. түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга: Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендә кабул ителгән “Кулланучылар хокукы турында”гы 2300-1нче Законында каралганча, кулланучыларның хокукларын яклау буенча чараларны тормышка ашыра”;

1.7. 71нче маддәдә:

1.7.1. 3 пунктны пункт түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга: “ Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастыру булып тиешле муниципаль берәмлектә тарала торган вакытлы матбугат басмасында аның тулы текстын беренче бастыру санала. Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастыру (халыкка белдерү) өчен шулай ук челтәр басмадан файдаланырга мөмкин. Муниципаль хокукый актның тулы текстын рәсми челтәр басмада бастырган ( урнаштырган) очракта графика күләмнәре һәм аларга таблица кушымталары китерелмәскә дә мөмкин.”;

. 1.7.2. 9нчы пунктта “шулай ук аларның проектларын,” сүзләреннән соң
“ җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр” дигән сүзләрне өстәргә,”.

2. Әлеге карар аны рәсми бастырганнан соң үз көченә керә, әлеге карарның 1.1.1, 1.2.1, 1.6.2, 1.6.4.1нче пунктчаларыннан кала, алар 2018 елның 30 декабрендә үз көченә керә һәм әлеге карарның 1.1.2 и 1.6.1нче пунктчаларыннан кала, алар 2019 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны закон тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

4. Татарстан Республикасы “Чистай муниципаль районы” муниципаль берәмлеге Уставына кертелгән үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне дәүләт теркәве узганнан соң масса-күләм мәгълүмат чараларында – “Чистопольские известия” газетасында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый-мәгълүматлар порталында бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлүенә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль
районы башлыгы                                                                 Д.А. Иванов